## 22. Тылсымлы “Туган тел “

Бик шатлыклы көнем бүген -
Чәчәк  аткан яран гөлем.
Сулар сипкән идем җырлап,
Тукайның мин “Туган тел”ен.

Минем бу гөлем, курәсең
Җырымны бик тә ошаткан.
Аннан шул моң тылсымыннан,
Күр, кыш көне чәчәк аткан.

Язлар җиткәч тә гөлемә,
Җырлармын туган телемдә.
Аннан һәйкәлгә илтермен,
Тукайның туган көнендә.

“И туган тел, и матур тел, әткәм әнкәмнең теле!”